## Ишниязова Энҗе Хәниф кызы сөйләгәннәрдән. (1971 елда туган)

### Мәктәптә укытучы булып эшли

“Урманасты Шынталы сигезьеллык мәктәбенең 3 классында укыган вакытта, 1980 елның 22 апрелендә пионер сафларына кабул ителдем. Мәктәпкә бөтенебез дә формадан йөрибез: кызлар көрән-кара күлмәк, ак яки кара алъяпкычтан, җиңнәрдә ак манжет, ак яка, малайлар зәңгәр костюм- чалбардан.Әгәр пионер икәнсең, галстук һәм значок һәрвакытта да булырга тиеш. Дружина Ю.А.Гагарин исемен йөрткәнгә күрә, бу шәхеснең тормышын җентекләп өйрәндек, һәр адымыбыз, эшебез белән аның исеменә тап төшермәскә тырыштык. Төрле кызыклы темаларга отряд сборлары үткәрелде. В.И.Ленинга багышланган альбомнар, стендлар эшләү буенча ярышлар оештырыла иде. Шулай ук кичәләр, концертлар күңелле үтә иде. Хәрби-патриотик тәрбия буенча да эш алып барылды, ел саен дружина “Аҗаган” уенында катнашты.”